**Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе**

**(Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе)**

БОЕРЫК

11.01.2016 Казан ш. № 12-07/1

**Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында” 14.05.2015 ел, № 341 Министрлар Кабинеты карары һәм “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет турында 18.11.2010 ел, № 906 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган “Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет турында типовой нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 05.09.2015 ел, № 643 Министрлар Кабинеты карары белән кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. “Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 22.04202015 ел, № 12-07/19 Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе каршында иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә дәүләт контрольлеген тәэмин итү буенча дәүләт сәясәтен формалаштыруда һәм тормышка ашыруда, шулай ук куллану базарында бозуларны кисәтү һәм юкка чыгаруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өлкәсендә (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эшчәнлеге өлкәсе) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган башка коммерциясез оешмаларның хокукларын хәл кылуга бәйле мәсьәләләрне карап тикшерүне хәл итә торган Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле

продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе (Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) каршында киңәшмә органы булып тора.”;

2.1 пунктның икенче абзацында “Россия Федерациясе” дигән сүзләрне төшереп калдырырга, “иҗтимагый берләшмәләр” дигән сүзләрдән соң “һәм дәүләтнеке булмаган башка коммерциясез оешмалар” дигән сүзләр өстәргә;

3.1 пунктта “социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар” дигән сүзләрне “иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциясе оешмалар” дигән сүзләргә алыштырырга;

3.2 пунктта “12” санын “5” санына алыштырырга;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.3. Иҗтимагый совет составына, шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм социаль юнәлешле башка коммерциясез оешмалар вәкилләре булып торучы гражданнар керергә мөмкин. Шул ук вакытта аларның һөнәри сыйфатлары, шул исәптән  Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен кирәкле булган тиешле белеме, әлеге өлкәдәге эш тәҗрибәсе исәпкә алына. Иҗтимагый совет составына, бу пунктының беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысын тәшкил иткән санда, затлар кертелә.”;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.4. Иҗтимагый совет әгъзалары булып Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар, суд карары нигезендә эшкә сәләтсез дип танылган затлар, хөкем карарын үтәмәгән яки хөкем карары үзеннән алынмаган затлар, шулай ук “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында” 4 апрель, 2005 ел, № 32-ФЗ Федераль закон нигезендә башка затлар Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары булып тора алмый.”;

3.5 пунктның икенче абзацында “хәл ителә” дигән сүзләрне “карала” дигән сүзгә алыштырырга;

3.6 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә;”;

3.8 пунктның дүртенче абзацында “кандидат вазыйфасына” дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“башкарма комитет инициативасы белән үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “түгәрәк өстәл”ләрдә һ.б.) катнашырга, дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан, персональ мәгълүматлар турында мәгълүматлардан һәм танышу өчен чикләнгән мәгълүматлардан файдалану белән бәйле рәвештә федераль законнар нигезендә катнашу чикләнелә торган чаралардан тыш;”;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясе инициативасы белән, “Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнелә торган, әлеге башкарма хакимият органнары каршында иҗтимагый советлар утырышларында башлангыч тикшермәгән килеш кабул ителә алмый торган норматив-хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында” 29.03.2013 ел, № 214 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы иҗтимагый совет утырышларында башлангыч тикшермәгән килеш кабул ителә алмый торган, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан эшләнелә торган, норматив-хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә күздә тотылган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе эшләгән норматив-хокукый актлар проектларына һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына

теркәүгә җибәрелә торган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосының норматив-хокукый актларына Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатыннан чыгып, үткәрелә.”;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.4. Иҗтимагый совет утырышлары, Иҗтимагый совет әгъзаларының ким дигәндә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, узды, дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасы утырышта шәхсән катнашу мөмкинлегенә ия булмаганда, үзенең тавышын һәм көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үзенең фикерен язмача рәвештә, Иҗтимагый совет рәисенә яки рәисе урынбасарына яисә Иҗтимагый советның җаваплы секретарена бу хакта алдан хәбәр итеп, факсимиль элемтә яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыруга хокуклы. Утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары исәбенә үзләренең тавышын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Бу Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив-хокукый актлар проектларын (норматив-хокукый актлар) Иҗтимагый совет тарафыннан карап тикшерү аларны Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы тарафыннан Иҗтимагый советка җибәрелгәннән соң ун календарь көне эчендә хәл ителә. Шул ук вакытта алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатыннан тавыш бирүне үткәрү, сорашып белешү нәтиҗәләрен беркетмәгә кертеп, Иҗтимагый советның барлык әгъзалары арасында сорашып белешү үткәрү рәвешендә читтән тавыш бирү юлы белән хәл

ителергә мөмкин, беркетмәгә Иҗтимагый совет рәисе, ә ул югында – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары кул куя. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон элемтәсе, электрон элемтә яки тапшырыла һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең тәңгәллеген һәм аларның документаль расланылышын тәэмин итә торган башка элемтә аша документлар алышу юлы белән хәл ителергә мөмкин. Читтән тавыш бирүне үткәрү очрагында Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, барлык әгъзаларына тәкъдим ителә торган көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирелергә тиешле норматив-хокукый акт проекты (норматив-хокукый акт) читтән тавыш бирүне үткәрү датасына җиде календарь көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә. Кирәк булганда, Иҗтимагый совет әгъзалары Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясеннән карап тикшерелә торган норматив-хокукый акт проекты (норматив-хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүматлар соратып ала.

Иҗтимагый совет карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә.”;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршында Иҗтимагый совет” бүлегенә урнаштырыла.”.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**